Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар Аты авыл җирлеге 2019 елның 08 июне

1. Гавами тыңлауларны уздыру нигезләре.
2. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар Аты авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре» проекты буенча гавами тыңлаулар (алга таба проект) РФ Шәһәр төзелеше кодексының 5.1., 30-32 статьялары, «РФда җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Арча муниципаль районы Утар Аты авыл җирлеге башлыгының 2019 елның 26 мартындагы 1 номерлы карары нигезендә үткәрелде.
3. Гавами тыңлауларда тәкъдим ителгән проект турында гомуми мәгълүмат.

Эшләү территориясе: Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар Аты авыл җирлеге.

Заказ бирүче: Арча муниципаль районы Утар Аты авыл җирлеге башкарма комитеты.

3. Гавами тыңлаулар үткәрү турында хәбәр итү рәвеше:

Проект материаллары Татарстан Республикасы рәсми хокукый порталында, авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырылды .

4. Гавами тыңлауларда катнашучылар:

- авыл җирлегендә яшәүчеләр.

5. Проект материаллары экспозициясен уздыру турында белешмәләр.

Проектның демонстрацион материаллары экспозицияләре авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырылды: ТР, Арча районы, Утар Аты авылы, Кооператив ур., 22 йорт; ТР, Арча районы, Орнашбаш авылы, Яшьләр ур., 6 йорт; ТР, Арча районы, Кушлавыч авылы, Тукай ур.,1 йорт.

Проектның төп материаллары авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм рәсми хокукый порталда урнаштырылды.

6. Гавами тыңлаулар уздыру турында белешмәләр.

Гавами тыңлаулар башлык карары белән расланган үткәрү графигы нигезендә үткәрелде.

Тыңлауларны уздыру срогы 07 июнь, 2019 ел.

Үткәрү урыны: Утар Аты авылы, Кооператив ур., 22, Утар Аты авыл мәдәният йорты.

7. Проект буенча искәрмәләр, тәкъдимнәр

- гавами тыңлаулар уздырганчы язма кисәтүләр һәм тәкъдимнәр килмәде;
- гавами тыңлаулар үткәрү барышында - кермәде.

8. Проект буенча гавами тыңлаулар беркетмәләре турында белешмәләр:

2019 елның 07 июнендәге 1 номерлы гавами тыңлаулар беркетмәсе.

9. Нәтиҗәләр һәм тәкъдимнәр:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар Аты авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре» проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү процедурасы Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының гамәлдәге законнары таләпләренә туры килә, шуңа күрә Утар Аты авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар узды дип санала.

2.Әлеге бәяләмә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, районның рәсми сайтында җирлекләр бүлегендә һәм авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында басылып чыгарга тиеш.

Гавами тыңлаулар үткәрү өчен җаваплы : Абдуллин Р.Г.

Гавами тыңлаулар секретаре: Фәйзрахманова Э.И.